**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

09.08.2022 679-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 21 октябрендәге 1166-п номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Угелводород чималы геологиясе бүлегенә (Т.П.Ахманова) эшләрнең югарыда күрсәтелгән Регламент нигезендә башкарылуын тәэмин итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И.Ткачук) әлеге боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гобәдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары
министрлыгының 2022
елның 09.08. №679-п
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

1) гидротехник корылма милекчеләре (гидротехник корылмага ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү хокукына ия булган муниципаль берәмлек, физик зат яки оешу-хокук формасына бәйсез рәвештә юридик зат);

2) эксплуатацияләүче оешмалар – гидротехник корылмаларны балансларында тотучы дәүләт яисә муниципаль унитар предприятиеләр яисә теләсә нинди оешу-хокук формасындагы оешмалар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле булып тиешле вәкаләтләрнең үзенә бирелүен раслый торган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән документлар нигезендә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык)

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында карар (алга таба – ихтимал зыян исәпләмәсе);

ихтимал зыянны исәпләмәсен килештерүдән баш тарту турында карар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Министрлык бланкында рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен түбәндәге ысуллар белән ала:

гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) аша җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе (ихтимал зыян исәпләмәсен килештерүдән баш тарткан очракта) мөрәҗәгать итүчегә шәхси кабинетка «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрының (алга таба – министр) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә;

«Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша (алга таба – Электрон документ әйләнеше);

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска);

Министрлыкка шәхсән килгәндә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яки кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

2.3.4. Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү кәгазенең титул битендә килештерү турында «Килештерелде» билгесе куела һәм Министрлыкның Герб мөһере белән раслана.

Ихтимал зыянның килештерелгән исәпләмәсен алу мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкта башкарыла.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы гариза һәм документлар кергән көннән башлап 30 календарь көн тәшкил итә, шул исәптән:

документларның комплектлылыгы һәм ихтимал зыян исәпләмәсе эчтәлегенең ихтимал зыян күләмен билгели торган норматив хокукый актлар нигезләмәләренә туры килүе турында тикшерү һәм карар кабул итү – биш календарь көн;

табигать тирәлегенә зыянны исәпләүнең дөреслеген тикшерү – җиде календарь көн;

ихтимал зыянны тәшкил итү күләмнәрен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында килештерү – 15 календарь көн.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән, шул исәптән электрон документ формасында да, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү

көнендә җибәрелә.

2.4.3. Министр яисә министр урынбасары тарафыннан имзаланган ихтимал зыян исәпләмәсенең кәгазь чыганактагы нөсхәләре мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать иткән көнне тапшырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Республика порталында урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Министрлык, дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлык вазыйфаи заты карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) түбәндәгеләрне тапшыра:

1) Гидротехник корылма хуҗасы тарафыннан имзаланган, Ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында гариза, иректе рәвештә;

2) Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы һәм Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Судно йөрешле гидротехник корылмалардагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2007 елның 2 октябрендәге 528/143 номерлы уртак боерыгы белән расланган Судно йөрешле гидротехник корылмалардагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян күләмен билгеләү методикасы, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Гидротехник корылмадагы (судно йөрешле һәм порттагы гидротехник корылмалардан тыш) һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2020 елның 10 декабрендәге 516 номерлы боерыгы белән расланган Гидротехник корылмадагы (судно йөрешле һәм порттагы гидротехник корылмалардан тыш) һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян күләмен билгеләү методикасы нигезендә башкарылган, кәгазь чыганакта өч нөсхәдә Ихтимал зыян исәпләмәсе;

3) Электрон чыганакта Ихтимал зыян исәпләмәсе.

2.6.2. Ихтимал зыян исәпләмәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

Гидротехник корылма хуҗасының исеме, аның реквизитлары; төзү датасы;

исәпләү өчен нигез;

гидротехник корылма хуҗасы тарафыннан исәп-хисапка җәлеп ителгән оешмаларның исеме һәм реквизитлары;

кулланыла торган норматив документлар һәм методик күрсәтмәләр, аларны куллануны нигезләү;

кулланылган башлангыч мәгълүматлар исемлеге, аларны алу чыганакларын күрсәтеп, кабул ителгән җитешсезлекләр; исәпләп чыгару тәртибе;

гидротехник корылмадагы һәлакәтләрнең сценарийларын тасвирлау һәм нигезләү;

гидротехник корылма персоналы, даими яшәүче халык һәм вакытлыча торучы халык арасында гидротехник корылмадагы һәлакәттә һәлак булу һәм зыян күрү ихтималы булган кешеләрнең ихтимал санын бәяләү;

гидротехник корылмадагы һәлакәттән социаль зыян күләменең акчалата чагылыштагы исәпләмәсе;

гидротехник корылмадагы һәлакәтләрдән төп мөлкәти зыянның акчалата чагылыштагы исәпләмәсенең күләме;

гидротехник корылмадагы һәлакәттән табигый тирәлеккә зыян күләме исәпләмәсе;

гидротехник корылмадагы һәлакәттән гомуми зыян күләменең акчалата чагылыштагы исәпләмәсе;

гидротехник корылмадагы һәлакәтләрдән ихтимал зыян күләменең акчалата чагылыштагы исәпләмәсе.

2.6.3. Ихтимал зыян исәпләмәсенә карата кушымталарда түбәндәгеләр булырга тиеш:

гидротехник корылманың планы;

гидротехник корылманың иң авыр һәм аеруча ихтимал һәлакәтләрендә һәлакәт йогынтысы зоналарының планнары;

гидротехник корылманың иң авыр һәм аеруча ихтимал һәлакәтләрендә һәлакәт йогынтысы зоналарының параметрларын исәпләү нәтиҗәләре;

Гидротехник корылмасы хуҗасының ихтыяры буенча башка мәгълүматлар, шул исәптән һәлакәтләре ихтимал зыян исәпләмәсенә кабул ителгән гидротехник корылманың аркылы кисемнәре.

2.6.4. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

шәхсән яисә мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат тарафыннан;

кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы аша;

Республика Порталы, Электрон документ әйләнеше системасы, электрон почта ярдәмендә электрон формада. Бу очракта ихтимал зыян исәпләмәсенең 3 нөсхәсе кәгазь чыганакта Министрлыкка кулдан җибәрелә.

2.6.5. Гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, физик затлар һшм шәхси эшкуарлар гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик багланышларын тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – бердәм система) теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең электрон документ рәвешендәге (электрон документ үрнәге) ышаныч кәгазе мондый документларны ясауга һәм имзалауга вәкаләтле булган затларның, шул исәптән нотариусның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныклана.

2.6.6. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар юк.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр категориясенә керми торган затның гариза белән мөрәҗәгать итүе;

электрон формадагы гариза һәм башка документлар 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен бозып, электрон имза белән имзаланган очракта;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы яки тулы күләмдә тапшырылмавы;

әлеге Регламентның 2.6.2 һәм 2.6.3 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрнең булмавы.

2.7.1. Әгәр дәүләт гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Әлеге Регламентның 3.7.2 пунктчасында күрсәтелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бер яки берничә органының ихтимал зыянны тәшкил итүче өлешләр күләмен килештерүдән баш тарту турындагы бәяләмәләрнең булуы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, сәбәпләрен күрсәтеп, министр урынбасары тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Республика порталындагы шәхси кабинетына, яисә гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне җибәрелә.

2.8.4. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кәгазь чыганакта гариза тапшырганда иң күп көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза гариза алынган көнне теркәлә. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.11.2. Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән Министрлык биналарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльнең нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

Гамәлдәге социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып тулысынча яраклаштырып булмаса, аларны реконструкцияләгәнчегә һәм капиталь ремонтлаганчыга кадәр, Министрлык Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренең берсе белән килештереп, мумөикн булган очракта, инвалидларның хезмәт күрсәтү урынына керүен тәэмин итү өчен чаралар күрергә яисә кирәкле хезмәтләрне инвалидның яшәү урыны буенча яисә дистанцион режимда күрсәтүне тәэмин итәргә тиеш.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

Министрлык биналарын һәм бүлмәләрен инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеген бирә торган башка шартлар үтәлешен тәэмин итү;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

3) Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталында шәхси кабинеттан, Министрлыкта алынырга мөмкин.

2.13.4. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелергә мөмкин.

2.14.3. Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза тапшыру эшләре) күпфункцияле үзәктә (алга таба – күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.

2.14.4. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм реестр язуларында

бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары

Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

3.2. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча юллау административ процедурасын тасвирлау

Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча җибәрү гамәлгә ашырылмый.

3.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) тапшырылган документларның комплектлылыгын, белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

4) ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында бәяләмә проектын әзерләү һәм аны Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына ведомствоара килештерүгә җибәрү;

5) документларны карау, Ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында карар кабул итү (яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар белән хат әзерләү);

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

7) техник хатаны төзәтү.

3.4. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү.

Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Республика порталыннан, Министрлыкның рәсми сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәтен үтәү вазыйфасы йөкләнгән Бүлек белгече (алга таба – Бүлек белгече) мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле башка мәсьәләләрдә.

Кирәк булганда, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.5. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) кәгазь чыганакта шәхсән, тапшыру турында белдерү белән заказлы почта юлламасы белән, электрон рәвештә Республика порталы, Электрон документ әйләнеше, яисә электрон почта аша әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, Министрлыкның документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә гариза бирә (җибәрә).

Гаризаны электрон формада җибәргәндә, ихтимал зыян исәпләмәсе электрон рәвештә теркәлә, ә ихтимал зыян исәпләмәсенең кәгазь чыганактагы 3 нөсхәсе Министрлыкка кулдан җибәрелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документлар килгән көндә башкарыла.

Әгәр ихтимал зыянны исәпләгәндә «Секретно» яшеренлек дәрәҗәсендәге мәгълүматлар кулланылса, документларны Министрлыкка тапшырганда кәгазь чыганактагы ихтимал зыян исәпләмәсе дәүләт сере турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, 8 нөсхәдә җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм материаллар.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;

электрон гариза формасын ача;

электрон гариза формасын тутыра;

ихтимал зыян исәпләмәсен электрон рәвештә беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү белешмәсен раслый (электрон гариза рәвешендә ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Формалаштырылган гаризаны форматы-мантыйгы ягыннан тикшерү мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасындагы барлык юлларны тутырганнан соң гамәлгә ашырыла. Гаризаның электрон формасындагы кырларны төгәлсез тутыру очрагы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткереп, хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка ихтимал зыян исәпләмәсенең 3 нөсхәсен кәгазь чыганакта кулдан җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

3.6. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.6.1. Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече Республика порталы аша документлар карау өчен алынганнан соң:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусын беркетә, ул Республика порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла;

документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә;

Бердәм порталга керү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган булса).

гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны Электрон документ әйләнешендә терки.

3.6.2. Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече, шәхсән мөрәҗәгать иткәндә документлар алынганнан соң, документлар почта аша, электрон почта аша җибәрелгәннән соң:

мөрәҗәгать итүнең предметын билгели, мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;

документларны тапшырган затның вәкаләтләрен тикшерә, документларның әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны Электрон документ әйләнешендә терки;

мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) гаризаның күчермәсен документларны кабул итү датасы турында тамгалап (шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) бирә яисә, телефон аша мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы, алынганда теркәлгән номеры турында хәбәр итә.

3.6.3 Документларны теркәгәннән соң, документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече:

гаризаны һәм документларны аларны карауны оештыру өчен Бүлек җитәкчесенә тапшыра.

гариза һәм документларны Электрон документ әйләнеше буенча Министрлыкның тиешле территориаль идарәсе (алга таба – территориаль идарә) җитәкчесенә җибәрә.

Зыян исәпләмәсен «Секретно» грифына ия булса, гариза һәм документлар Министрлыкта яшеренлек режимын тәэмин итүче белгечтә теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көндә башкарыла.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән, Бүлек җитәкчесенә һәм Министрлыкның территориаль идарәсе җитәкчесенә тапшырылган документлар.

3.7. Тапшырылган документларның комплектлылыгын, белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү.

3.7.1. Бүлек җитәкчесе гаризаны һәм документларны карау өчен җаваплы башкаручы (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм тиешле карар кабул итү өчен тапшырылган материалларны аңа тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

3.7.2. Бүлек белгече түбәндәгеләрне тикшерә:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның комплектлылыгын

әлеге Регламентның 2.6.2 һәм 2.6.3 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрне тикшерә.

3.7.3. Документлар комплектлы булмаган очракта яки ихтимал зыян исәпләмәсендәге белешмәләр туры килмәгәндә, бүлек белгече документларны кире кайтару турында карар проекты әзерли һәм тапшырылган документлар белән аны, килештерү өчен, бүлек җитәкчесенә бирә.

Әлеге Регламентның 3.7.2-3.7.3 пунктларында билгеләнә торган процедуралар зыянны килештерү турында гаризаны теркәлгән мизгелдән алып дүрт календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.7.4. Бүлек җитәкчесе документларны кире кайтару турында карар проектын килештерә һәм аны, документлар белән, Минерал чимал һәм су ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) җитәкчесенә имзалау өчен юллый.

3.7.5. Идарә җитәкчесе документларны кире кайтару турында карар проектын килештерә һәм аны, документлар белән, министрның вәкаләтле урынбасарына (алга таба – министр урынбасары) имзалау өчен җибәрә.

3.7.6. Министр урынбасары документларны кире кайтару турындагы карарны имзалый.

3.7.4, 3.7.5 һәм 3.7.6 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар документларны кире кайтару турында карар проекты килештерүгә кергән көнне, ләкин бер календарь көннән дә артмаган чорда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе: документларны кире кайтару турында теркәлгән карар.

3.8. Ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында карар проектын әзерләү һәм аны Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына электрон документ әйләнешендә ведомствоара килештерүгә җибәрү.

3.8.1. Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән баш тарту нигезләре булмаса, Министрлыкның территориаль идарәсе белгече су басу зонасында әйләнә-тирә мохитнең потенциаль пычрану чыганаклары: канализация челтәрләре, ягулык-майлау материаллары складлары, минераллы ашламалар, калдыкларны туплау урыннары турында Бүлек җитәкчесе адресына тиешле бәяләмә әзерли. Кирәк булганда, урынга чыга.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач өч календарь көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.8.2. Бүлек белгече, Министрлыкның территориаль идарәсе мәгълүматын исәпкә алып, табигать тирәлегенә зыян исәпләмәсен карый, тикшерә һәм ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында карар проектын әзерли.

Бүлек белгече ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында карар проектын һәм тармакка караган зыян төрләре буенча Методикаларга туры килүе өлешендә тикшерү өчен ихтимал зыян исәпләмәсен электрон документлар әйләнешендә Татарстан Республикасының түбәндәге башкарма хакимияте органнарына җибәрә:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына – су белән тәэмин итүне бозу аркасында торак фондына китерелгән зыянны килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына – транспорт элементларына китерелгән зыянны килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына – элемтә элементларына китерелгән зыянны килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына – урман фондына урманны чимал буларак югалтудан, шулай ук урманнарны су басудан һәм һәлакәттән килгән зыянны килештерү өчен;

Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына – предприятиеләрнең төп һәм әйләнеш фондларына, предприятиеләрнең әзер продукциясенә китерелгән зыянны килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына – авыл хуҗалыгы җитештерүенә булган зыянны килештерү өчен;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына – социаль зыян исәпләмәсен карау һәм тикшерү өчен;

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына – балык хуҗалыгына зыян исәпләмәсен килештерү өчен.

Ихтимал зыян исәпләмәсендә «Секретно» грифы булган очракта, ихтимал зыян исәпләмәсе яшеренлек режимын тәэмин итүче белгеч тарафыннан килештерүче Министрлыкларның тиешле хезмәтләренә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң дүрт календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына электрон документлар әйләнешендә яки яшеренлек режимын тәэмин итүче хезмәтләр аша ведомствоара килештерүгә җибәрелгән карар проекты.

3.8.3. Башкарма хакимият органнары тармакка караган зыян төрләре буенча ихтимал зыян исәпләмәсен карыйлар, Электрон документ әйләнешендә Министрлык карарын килештерәләр (килештермиләр). Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының кисәтүләре килештерү кәгазендә күрсәтелә.

Ихтимал зыян исәпләмәсендә «Секретно» грифы булган очракта, килештерүче министрлыклар килештерү (килештермәү) турындагы карарны министрлыкларда яшеренлек режимын тәэмин итүче хезмәтләр аша тапшыралар.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедураның вакыты алдагы процедураны тәмамлаганнан соң 15 календарь көн тәшкил итә.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан ихтимал зыянны исәпләүне Килештерү (килештерү) турында карар.

3.9. Документларны карау, ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында карар кабул итү (яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар белән хат әзерләү).

3.9.1. Министр (министрның вәкаләтле урынбасары) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының электрон документ әйләнешендә килештерелгән, ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турындагы карарны имзалый.

Ихтимал зыян исәпләмәсе уңай килештерелгән очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан ихтимал зыян исәпләмәсенең барлык нөсхәләрендә титул битендә килештерү турында «Килештерелде» билгесе куела һәм герб мөһере белән раслана.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында карар килештерелгән көннән алып календарь көннәрдә исәпләнелә торган өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.9.2. Әлеге Регламентның 3.8.2 пунктчасында күрсәтелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан ихтимал зыян исәпләмәсе буенча кисәтүләр алынса, Бүлек белгече Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан җиткерелгән кисәтүләрне гомумиләштерә, ихтимал зыян исәпләмәсен килештерүдән баш тарту турында карар проекты (алга таба – баш тарту турында карар проекты) әзерли һәм, имзалау өчен, Электрон документ әйләнешендә аны Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү турында карар алынганнан соң ике календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.9.3. Бүлек җитәкчесе баш тарту турында карар проектын карый, аны килештерә һәм Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесенә җибәрә.

3.9.4. Идарә җитәкчесе баш тарту турында карар проектын карый, аны килештерә һәм, имзалау өчен, министрның вәкаләтле урынбасарына җибәрә.

3.9.5. Министр урынбасары баш тарту турында карар проектын имзалый һәм аны документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.9.3, 3.9.4, 3.9.5 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар баш тарту турында карар кергән көнне, ләкин бер календарь көннән дә артык булмаган көндә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе: документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә җибәрелгән, ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү (килештерүдән баш тарту) турында имзаланган карар.

3.10. мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече электрон документ әйләнешендә ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү (килештерүдән баш тарту) турында карарны терки һәм аны гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның вәкаләтле вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар бәяләмәгә кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе: теркәлгән һәм мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирелгән (җибәрелгән) бәяләмә.

Ихтимал зыян исәпләмәсенең имзаланган, кәгазь чыганактагы нөсхәләре мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать иткән көнне тапшырыла.

3.11. Техник хаталарны төзәтү.

3.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу, басма хаталары, грамматик яки арифметик хаталары) булган документ;

техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә), Республика порталы аша җибәрелә.

3.11.2. Министрлыкның документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.11.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып, тапшыра яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша, Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң 3 календарь көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Административ регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган идарәләрнең (бүлекләрнең) җитәкчеләре тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контроль тәртибе һәм формалары

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

- эшнең алып барылуына;
- документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;
- документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;
- дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) шушы Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен үтәү өчен шәхсән җаваплы булалар.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның шәхси җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә беркетелә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контроль тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлегендә мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту даими, һәрьяклы һәм объектив булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын һәм тәртибен камилләштерү буенча тәкъдимнәр, тәкъдимнәр белән индивидуаль һәм күмәк мөрәҗәгатьләр, шулай ук вазыйфаи затлар тарафыннан административ регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларны бозу турында белдерү һәм шикаятьләр җибәрергә хокуклы.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлык хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи заты, Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

3) гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны Мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталрны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда Мөрәҗәгать итүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, «Интернет» челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru) файдаланып җибәрелә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул итеп алына ала.http://eco.tatarstan.ruhttps://uslugi.tatarstan.ru

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать

итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы орган, вазыйфаи зат яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органның, органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерү турында, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка формаларда да;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача формада яки, аның ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.12. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять

белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына

________________________________

Кемнән____________________________

(шәхси эшкуарлар өчен: Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), адрес (почта һәм (яки) электрон)

________________________________

юридик затлар өчен: оешма атамасы, адресы (почта һәм (яки) электрон)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

______________________________________________________________________________

*(дәүләт хезмәте атамасы)*

Язылган:______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат: _______________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Техник хатаны төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.____________________________________________________________________________

2.____________________________________________________________________________

3.____________________________________________________________________________

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карар хакында:

e-mail:________________________________________ адресына электрон документ рәвешендә;

______________________________

____________________________________________________________________________

адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

________________________________________________________________________________

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне дә кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, файдалана алмаслык итүгә, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) үз ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның риза булуы хакында раслыйм.

| ___________________ | ___________________ | ___________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) |

Татарстан Республикасы территориясендә гидротехник корылмадагы һәлакәт нәтиҗәсендә физик затларның гомеренә, сәламәтлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә китерелергә мөмкин булган ихтимал зыян исәпләмәсен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 267-68-01 | eco@tatar.ru. |
| Министр урынбасары | 267-68-60 | Ilnur.Gubaydullin@tatar.ru |
| Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе | 267-68-95 | Aleksey.Chinarev@tatar.ru |
| Углеводород чималы бүлеге җитәкчесе | 267-68-96 | Tatyana.Ahmanova@tatar.ru |
| Эшчәнлек башкару бүлеге җитәкчесе | 267-68-04<br>267-68-05 | eco@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты биләмәләреннән, табигать ресурсларынан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге җитәкчесе | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar. ru |